| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
05.03.2021

КАРАР
№ 249-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 28 гыйнварындагы 40 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.
2. Түбәндәгеләрне расларга:
– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясе составы (кушымта итеп бирелә);
– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясе эшенең регламенты (кушымта итеп бирелә).
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясе вәкаләтләре чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм биш ел тәшкил итә.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:
- “Административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру турында” 2006 елның 31 мартындагы 109-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 17 июлендәге 308-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 24 мартындагы 170-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 23 сентябрендәге 738-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 9 декабрендәге 1584-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2011елның 11 апрелендәге 224-п номерлы карары;
- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2012 елның 30 маендагы 630-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 28 мартындагы 373-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 15 маендагы 595-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 11 сентябрендәге 1137-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 17 октябрендәге 1364-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 12 декабрендәге 1575-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 20 мартындагы 294-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 31 декабрендәге 1524-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 1 мартындагы 245-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 10 июнендәге 716-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 2 февралендәге 89-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 5 мартындагы 251-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 3 ноябрендәге 1636-п номерлы карары;

- “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын раслау турында” 2019 елның 15 гыйнварындагы 17-п номерлы карары;

- “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 15 апрелендәге 594-п номерлы карары.

5. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 5 мартындагы
249-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Ишниязов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Латыйпов С. З. | Саба районы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары, полиция майоры, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Галиуллин А.М. | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисенең икенче урынбасары (килешү буенча); |
| Галиев И.И. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Административ комиссиясе баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Билалов Р.М. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Үзәк территориаль идарәсенең 3 нче разрядлы өлкән белгече (килешү буенча); |
| Рамазанов Э.Д. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |
| Шәймәрданов М.Т. | “Торак” ипотека торак займы фонды директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 5 мартындагы
249-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының административ комиссиясе “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелгән.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларны оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора. Административ комиссиянең бурычлары булып, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә административ хокук бозулар турында һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.4. Административ комиссияне төзү һәм оештыру буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.5. Административ комиссиянең герб мөһере һәм чыгымнар сметасы бар. Финанслау муниципаль район Башкарма комитеты аппараты аша тәэмин ителә.

1.6. Административ комиссияне төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тикшереп тора.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру.

2.1. Административ комиссия муниципаль районның Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә торган рәистән, рәис урынбасарларыннан, җаваплы сәркатиптән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба - административ комиссия әгъзалары) тора.

2.2. Административ комиссия рәисе административ комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра, административ комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга, беркетмәләргә, тәкъдимнәргә кул куя, ә ул булмаганда әлеге бурычлар рәис урынбасарының берсенә йөкләнә.

2.3. Административ комиссия эшен оештыру административ комиссия рәисенә йөкләнә. Административ комиссия белән рәис җитәкчелек итә. Моннан тыш, эшне оештыруда рәис урынбасарлары, җаваплы сәркатип, комиссия әгъзалары һәм муниципаль берәмлек муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары катнаша. Рәис ризалыгы белән кирәк булганда, комиссияләр эшендә башка затлар да катнаша ала.

2.4. Даими штат нигезендә комиссия составына комиссиянең җаваплы сәркатибе керә. Җаваплы сәркатип булмаганда, аның бурычлары вакытлыча административ комиссия рәисе тарафыннан сайланган комиссиянең теләсә кайсы әгъзасына йөкләнә. Административ комиссиянең башка әгъзалары иҗтимагый башлангычларда административ комиссиядә эшлиләр.

2.5. Административ комиссияләрнең санлы составы муниципаль районның Башкарма комитеты тарафыннан кимендә 5 әгъза күләмендә билгеләнә һәм төгәл сан тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Административ комиссия әгъзалары административ хокук бозу турындагы эшләрне караганда тигез хокукларга ия.

2.7. Административ комиссия үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

2.8. Административ хокук бозу турындагы эшне башкаруга кабул иткән җаваплы сәркатип административ комиссия утырышында аны карап тикшерүгә тиешле әзерлек үткәрә.

2.9. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

2.10. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты, административ комиссиянең үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын, административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча билгеләп куярга тиеш.

2.11. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы сәркатипнең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.12. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.13. Административ комиссия адресына килгән шикаятьләр һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.14. Муниципаль район административ комиссияләренең документларын (актлар, беркетмәләр, карарлар, билгеләмәләр, бәяләмәләр, гариза, язышу) саклау срогы 5 ел тәшкил итә, саклау срогы тәмамланганнан соң, документлар юкка чыгарылырга тиеш.

## 3. Административ комиссияне чакыру һәм утырышны уздыру тәртибе

3.1 Административ хокук бозулар турында эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр утырышларда административ комиссия тарафыннан карала. Административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы карар аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда - рәис урынбасарларының берсе тарафыннан ,административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, ләкин атнага кимендә бер тапкыр, кабул ителә .

3.3. Административ комиссия утырышында административ комиссия рәисе, ә ул булмаганда - административ комиссия рәисе урынбасарларының берсе рәислек итә.

3.4 Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, ачык һәм хәбәрдар рәвештә алып барыла.

3.5. Әгәр административ комиссия утырышында административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3.6. Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео- һәм фотога төшерү административ комиссия рәисе рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

3.7 Административ комиссия карары буенча аның утырышлары ябык булырга мөмкин. Аларда бары тик административ комиссия әгъзалары, хокук саклау органнары җитәкчеләре һәм махсус чакырылган затлар гына катнашырга хокуклы.

3.8 Административ комиссия утырышын әзерләүне җаваплы сәркатип башкара, ул карауга билгеләнгән эшләр исемлеген төзи, эшне карау мөмкинлеге турында рәискә хәбәр итә, якларның килүен һәм вәкилләрнең вәкаләтләрен, шулай ук өстәмә материаллар керүне тикшерә.

3.9 Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе административ комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә өч көн кала хәбәр итә.

3.10 Административ комиссия утырышында катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы сәркатибенә, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышы көненә кадәр өч эш көнендә хәбәр итәргә тиеш.

3.11.Административ хокук бозу турындагы эшне тикшерү өчен билгеләнгән вакытта рәис комиссия утырышын ача, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокук һәм бурычларын аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, утырышны алып баруның административ процесста катнашучыларның гаризалары, үтенечнамәләре булу-булмавын ачыклый, утырыш белән җитәкчелек итә, эшнең барлык шартларын тулысынча һәм һәрьяклап ачыклауга ярдәм итә, утырышта тиешле тәртип тәэмин итә.

3.12 Беркетмәне карау административ материалның шартлары турында рәислек итүче докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң, административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.13 Административ комиссия карарларына административ комиссия рәисе һәм административ комиссиянең җаваплы сәркатибе имза сала.

3.14 Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә, утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.15 Административ комиссиянең һәр утырышында җаваплы сәркатип тарафыннан беркетмә алып барыла. Беркетмә административ комиссия утырышы

тәмамланганнан соң 3нче көннән дә соңга калмыйча әзерләнергә һәм имзаланырга тиеш

3.16 Комиссия утырышлары, җаваплы сәркатип тәкъдиме буенча, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт белән, кагыйдә буларак, 15 көнгә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышларын рәис , ә ул югында рәис урынбасарларының берсе алып бара.

**4. Административ комиссия карары турында.**

4.1. Административ комиссия карары рәис тарафыннан игълан ителә һәм имзалана.

4.2 Карарның күчермәсе өч көн дәвамында административ комиссия карары чыгарылган затка тапшырылырга яисә җибәрелергә тиеш.

4.3 Административ комиссиянең закон көченә кергән карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

4.4 Карарның үз вакытында бирелүен һәм карарларның күчермәләрен җибәрүне контрольдә тоту җаваплы кешегә, административ комиссиянең сәркатибенә йөкләнә.

4.5. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр яисә протестлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

**5. Административ җәза салу турындагы карарның үтәлеше.**

5.1. Административ хокук бозу турындагы эш буенча административ комиссия карары барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, юридик затлар тарафыннан үтәлү өчен мәҗбүри.

5.2. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар аның законлы көченә кергәннән соң үтәлергә тиеш.

5.3. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан административ штраф салу турында карар законлы көченә кергән көннән алтмыш көннән дә соңга калмыйча яисә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 31.5 статьясында каралган срок чыкканнан көннән соң түләнергә тиеш.

5.4. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан банкка, башка кредит оешмасына яки ТР Дәүләт хезмәте порталы аша кертелә яки күчерелә.

5.5. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга шикаять карар күчермәсен тапшырган көннән яисә алган көннән алып ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин.

5.6. Административ штрафны түләү турында таныклаучы документ булмаганда, карар законлы көченә кергән көннән алтмыш көн узгач, административ комиссия федераль законнарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен суд приставына-башкаручыга тиешле материалларны җибәрә.

5.7. Штраф салу рәвешендә административ җәза гаепле затларны җибәрелгән хокук бозуларны бетерү зарурлыгыннан азат итми.

5.8. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эш оештыра.